Шәһәр күләмендә география фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың мәктәп этабы биремнәре
2022-2023 нче уку елы
9 нчы сыйныф

Эш вакыты – 120 минут
Гомуми балл – 80

1. Иң арзанлы электр энергиясе кайсы станциядә җитештерелә? *(2 БАЛЛ)*
1. АЭС 2. ГЭС 3. ТЭС

2. Дөрес җавапларны туры китерегез *(2 БАЛЛ)*

Район	*Ягулык төре*
1. Печора бассейны	А. Нефть
2. Уренгой чыганагы	Б. Табигый газ
3. Идел-Урал базасы	В. Көрән күмер
4. Мәскәү яны бассейны	Г. Ташкүмер

3. Россиядә табигый газ табуның иң зур үзәге: *(2 БАЛЛ).*
1. Якутия 3. Көнбатыш Себер
2. Оренбург-Әстерхан (Астрахань) 4. Мәскәү яны бассейны

4. Хәзерге заманда алдынгы җитештерү тармагы: *(2 БАЛЛ)*
1. төп химия
2. автомобильләр җитештерү
3. ташкүмер сәнәгате (промышленносте)
4. электрон сәнәгате

5. Тимер рудасы чыганаклары: *(2 БАЛЛ)*
1. Михайлов, Хибин, Джидин; 3. Качканар, Таштагол, Ковдор;
2. Яковлев, Лисаков, Депутат; 4. Качканар, Коршун, Шерегеш;

6. Ерак Көнчыгышта металлны яңадан эшкәртү буенча металлургия үзәге булып санала торган шәһәр: *(2 БАЛЛ).*
1. Красноярск
2. Хабаровск
3. Амурдагы Комсомольск
4. Владивосток

7. Россиядә иң арзанлы ташкүмер табу бассейны: *(2 БАЛЛ).*
1. Лена 3. Канск-Ачинск
2. Донецк 4. Печора

8. Түбәндәгеләрдән кайсысы ягулык-энергетика комплексына керми? *(2 БАЛЛ)*
1. электр энергетикасы 3. табигый газ
2. ягулыкны транспортлау 4. кокслана торган химия

9. Илнең нефть үткәргеч системасы үзәге кайда урнашкан? *(2 БАЛЛ)*
1. Казан 2. Әлмәт 3. Мәскәү 4. Астрахань

10. Россиянең иң зур ГЭСлары ике елгада урнашкан. Алар кайсы елгалар? *(4 БАЛЛ)*
1. Енисей 3. Дон 5. Ангара
2. Обь 4. Лена

11. Түбәндәгеләрдән кайсы төбәктә АЭС юк? *(2 БАЛЛ)*
1. Саратов өлкәсе 3. Чукот АӨ
2. Свердлов өлкәсе 4. Ненец АӨ

12. Түбәндәгеләрдән кайсы шәһәрдә диңгез суднолары җитештерелми? *(2 БАЛЛ)*
1. Калининград 2. Новороссийск 3. Мурманск 4. Владивосток

13. Түбәндәге раслауларның кайсыларын хаталы дип саныйсыз? *(10 БАЛЛ)*
1. Россиядә дүрт бөртекле ашлык җитештерү үзәге бар: Төньяк Кавказ, Себер көньягы, Кара туфраклы Үзәк һәм Көньяк Урал.
2. Арпаны бар урында игәләр, ул тундра һәм урман-тундра зонасында күбрәк җыеп алына.
3. Россия чәй үстерүче илләр составына керми.
4. Сөт терлеге урман зонасында, сусыл азык белән тәэмин ителә, ә ит терлеге исә урман-дала һәм дала зонасына урнашкан.

14. Дөрес җавапларны туры китерегез *(2 БАЛЛ)*.

Ашлама төре	*Җитештерү үзәге*
1. Фосфорлы	А. Березники
2. Азотлы	Б. Воскресенск
3. Калийлы	В. Череповец

15. Дөге үстерү буенча специальләшә: *(2 БАЛЛ)*.
1. Приморье крае һәм Белгород өлкәсе;
2. Дагестан һәм Чувашия Республикалары;
3. Краснодар һәм Алтай крайлары;
4. Астрахань һәм Ростов өлкәләре.

16. Мәскәү шәһәрендә 14:00 сәгать (көндезге сәгать ике) булганда, Якутск шәһәрендә сәгать ничә була? *(5 БАЛЛ)*.

_____

17. Россиядә нефть чыгару азая, ә табигый газ табу зур тизлек белән арта бара? Моның сәбәбе нидә? *(5 БАЛЛ)*

_____
_____
_____
_____
_____

18. Әлеге контурлы картада алмаз табу чыганакларының төп регионнарын махсус кабул ителгән шартлы билгеләр белән күрсәтегез, ин куп табыла торган регионнын чыганак атамаларын языгыз. *(10 БАЛЛ)*



19. Бирелгән раслауларнын кайсыларын дөрес дип саныйсыз? *(10 БАЛЛ)*

1. Нефть эшкәртү заводлары, башлыча, илнең Европа өлешендә урнашканнар.
2. Иң түбән җылылык коэффициеты ташкүмердә.
3. Сланец сәнәгате (промышленносте) ягулыкка керә.
4. “Зәңгәр агым” газүткәргече Каспий диңгезе аша үтә.
5. Җылылык электр станцияләрендә (ТЭЦ) электр энергиясе белән беррәттән кайнар су һәм пар барлыкка килә.
6. Россиянең бердәм энергия системасы электр энергиясен Кытайга да бирә.

20. Түбәндәгеләрдән кайсылары дөрес булуын билгеләгез. *(10 БАЛЛ)*

1. Россиядә чыгым китерә торган шахта һәм карьерларны бетерә баралар.
2. Җылылык электр станцияләре (ТЭЦ), бик күп каты һәм газсыман калдыклар аерып чыгаралар.
3. Илдә иң зур запаслы ташкүмер бассейны – Донецк ташкүмер бассейны.
4. Тикшерелгән табигый газ чыганакларының, бары тик яртысы гына актив кулланылышка керә.
5. Согуд Гарәбстанының табигый газ запасы Россиянекеннән күбрәк.
6. Җылылык-энергетика комплексы составына ягулыкны табу һәм электр энергиясе эшләп чыгару керә.
7. Нефтьнең җылылык коэффициенты ташкүмергә караганда өстен.